ОНЛАЙН СӘҮДӘ

Татарстанда 45 меңнән артык сатучы өйдә торып акча эшли

> 2

ӨЗЕЛМӘС ҖЕП

Мөхәммәтшиннар ике яктан да әти-әниләре белән киңәш-табыш итеп яшиләр

> 3

ЯШЕЛ ШӨГЫЛЬ

Чаллыда яшәүче Фәридә Байбикова кечкенә фермасында микроящеллек үстерә

> 4

СОҢГЫ УЕН

«Ак барс» капитаны Данис Зарипов тамашачы белән саубуллашты

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 28 (28995) | Сишәмбе | 28 февраль | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Лилия ГЫЙМАЗОВА

ИСТӘЛЕККӘ – ТАКТА

ЮНЫС ӘХМӘТҖАНОВНЫҢ ТОРМЫШКА АШКАН ХЫЯЛЫНА БҮГЕН КЕМ ХУҖА?

Тәмле ашлар җырчысы, татар ашларының атасы, чын оста һәм остаз. Бу сүзләр – танылган аш-су остасы Юныс Әхмәтҗанов турында. 28 февральдә аның тууына 96 ел тула. Кызганыч, кыска гына гомерен һәм бөтен барлыгын татар халык ашларын өйрәнүгә, туплауга һәм бөтен дөньяга танытуга багышлаган шәхеснең мирасы бүген аяныч хәлдә...

Хыял туганда

Теләче районының Олы Кибәхуҗа авылында туып, өч яшеннән Казанда яшәгән егет хезмәт юлын Бөек Ватан сугышының иң катлаулы чоры – 1942 елда завод ашханәсендә башлый. Ул чакта Юныска нибары 15 яшь була. Әмма, яшь булуына карамастан, авыл һәм шәһәрдә яшәүче татарларның туклану рәвешләрен, халык ризыкларын пешерү серләрен өйрәнергә тотына ул. 24 яшендә егетне Казан ашханәләре һәм кафеларында производство мөдире итеп билгелиләр.

1959 елда тәүге китабы дөнья күрә. Юныс Әхмәтҗановның «Татар халык ашлары» китабын кулына алмаган хуҗабикәләр, ул китапны сакламаган гаиләләр Татарстанда бик сирәктер. Әмма аш-су остасы моның белән генә тукталып калмый, татар авыллары буенча йөреп, бөртекләп диярлек рецептлар җыя һәм бер-бер артлы китаплар әзерләвен дәвам итә. «Ашларыбызга гына игътибар итегез: токмачын аласыңмы, бәлешен яки татлыдан-татлы чәй ашларын әйтәсеңме – барысы да чын сәнгать әсәрләре бит алар. Белергә, өйрәнергә, шуларны табыннарыбыз күрке итү өчен, тырышып хезмәт итәргә генә кирәк», – дип яза аш-су остасы үзе.

Юныс Әхмәтҗанов 1969 елда тормышындагы иң зур хыялын чынга ашыра – Советлар Союзындагы беренче Татар ашлары йортын ачуга ирешә. Бүген Казанның үзәк урамында урнашкан әлеге бинада Юныс ага хөрмәтенә ачылган истәлек тактасы гына эленеп тора...

Хыял үлгәндә

Татар ашлары йорты – ярты гасырдан артык эшләп, 2020 елда ябылган Казанның легендар рестораны.

– Заманында бөтен Татарстанны ашаттык инде без, – ди Юныс Әхмәтҗанов белән бергә 15 еллап эшләгән аш-су остасы, «тәмле» китаплар авторы Зөһрә Камалова. – Юныс абыйның кулы астына эләккәнгә, аның белән бергә эшләгәнгә бик бәхетле мин. Әмма Татар ашлары йортының язмышы өчен бик кайгырам. Юныс абый бакыйлыкка күчкәннән бирле тәртип булмады кебек инде анда... Яхшы җитәкче кирәк шул мондый җиргә.

Юныс ага өчен кадерле булган Татар ашлары йортының соңгы еллардагы язмышы өчен әле берәү, әле икенче берәү җаваплы булып карады. Әмма заманында шәһәр халкы һәм кунакларының яраткан урыннарының берсе булган әлеге бинаның ишекләре инде шактыйдан бикле. Ә күптән түгел генә аны Бауман урамындагы «Музей иллюзий»,

protatarstan.ru

«Дом вверх дном» һ.б. күңел ачу үзәкләренең хуҗасы, эшмәкәр Александр Донской сатып алган. Хәзер Татар ашлары йортының киләчәге – яңа хуҗа кулында. Аның үткәне белән танышырга өлгергән эшмәкәр бу бинаны нишләтмәкче була икән? Бу сорауны үзенә бирдек.

– Нәтиҗәсен төгәл генә әйтә алмыйм, әмма ул күңел ачуга юнәлдерелгән проект булачак. Моңарчы бер җирдә дә күренмәгән яңа форматлар кулланырга ниятлим. Хәзерге вакытта мин Япония, АКШ, Гарәп Әмирлекләренә сәфәр кылып, бу проект өчен кызыклы идеяләр эзлим, – диде ул. – Ни өчен Казанмы? Чөнки Татарстан башкаласы туристлар саны буенча – алдынгылар рәтендә. Ә Бауман урамы – монда килгән кунакларның иң яраткан урыны. Шуңа да мин бу бинаны сатып алырга булдым. Аның тарихын, эчтәлеген беләм, хәтта мондагы мохитне саклау теләге дә бар иде. Әмма мин – татар түгел. Шуңа да миңа сезнең милли традицияләрне аңлау, аеруча саклау бик авыр.

Шулай итеп, инде әйткәнебезчә, Татар ашлары йортында Юныс Әхмәтҗановның эзе истәлек тактасы рәвешендә генә калды.

– Татар ашлары йортының өске катында Юныс абыйның музей кебегрәк эшләнгән хәтер почмагы бар иде.

> **ЮНЫС ӘХМӘТҖАНОВ КУЛЪЯЗМАЛАРЫННАН**
> Пешекче – артист ул, кунагының күңелен табу өчен, аңа, нәкъ сәхнәдәгечә, сәнгать остасы булырга туры килә. Бәлки эчеңдә әллә нинди кайгы бардыр, әмма син аны сиздермисең. Йөзеңдә һәрчак елмаю. Усалланып йөрүче кеше тәмле аш пешерә белми ул. Пешекче – табиб. Аңа кешенең сәламәтлеге тапшырылган. Пешекче – рәссам. Аның ашы тәмле генә түгел, бик матур да булырга тиеш. Пешекче – философ та, педагог та, сәгатьләр буе утлы плитә янында торучы металлург та.
>
> Чын оста, ул кайсы һөнәргә ия булса да, үз хезмәтен үзе мәңгеләштерә ала. Пешекче элек-электән үк ирләр эше булып саналган, чөнки авыр хезмәт ул. Минем өчен пешекче эше – җан рәхәте.

Әйберләр күп иде анда, тулы бер музей ачарлык. Ачарга кирәк тә! Һич югы ул хәтер почмагы Татар ашлары йортында сакланырга тиеш. Яңа хуҗа 15 квадрат метр урынын кызганмас әле. Юныс абый – бу бинага нигез салучы бит! – диде Зөһрә ханым Камалова.

Ахыры 4 нче биттә >

Яңа юл быел ачыла

«Автодор» дәүләт компаниясе Мәскәү белән Казанны тоташтырачак М12 «Восток» түләүле юлын быел тулысынча файдалануга тапшыруны күздә тота. Компания башлыгының беренче урынбасары Игорь Коваль әйтүенчә, трассаны Екатеринбургка кадәр 2024 елда төзеп бетерү планлаштырыла.

Исегезгә төшерәбез: 811 чакрым озынлыктагы М12 автомобиль юлы Мәскәү, Владимир, Түбән Новгород өлкәләре, шулай ук Чувашия, Татарстан аша уза. Ул 17 зур төбәк үзәген берләштерәчәк. Трасса Россиянең Европа өлешендәге автомобиль юллары челтәренә (М11 «Нева», М4 «ДОН» һ.б.) тоташтырылачак. Киләсе елда Екатеринбургка кадәр төзелеп беткәч, түләүле магистральнең гомуми озынлыгы 1,6 мең чакрым чамасы тәшкил итәчәк.

Табигать өчен миллиардлар

Татарстанда «Экология» илкүләм проекты кысасында табигатьне саклау буенча барлыгы 29 чара гамәлгә ашырылган. Моның өчен 14 миллиард сумнан артык акча тотылган. Республика 2019 елдан бирле проектны гамәлгә ашыруда актив катнашып килә.

Экология һәм табигать ресурслары министры урынбасары Егор Тарнавский әйтүенчә, соңгы биш ел эчендә табигатьне саклау җәһәтеннән барлыгы 850 чара (52 миллиард сумлык) үткәрелгән. Күпчелеге – «Экология» илкүләм проекты буенча. Татарстан «Иделне савыктыру», «Чиста ил», «Урманнарны саклау», «Чиста су», «Каты көнкүреш калдыклары белән эш итүнең комплекслы системасы» кебек федераль проектларда катнаша.

Исегезгә төшерәбез: илкүләм проектлар Президент Владимир Путин тәкъдиме белән тормышка ашырыла.

Яз салкын алып килә

Бу араларда Татарстанда циклон хакимлек итә: кар-буран, секундына 15–20 метр тизлектә җил. Шул ук вакытта язның беренче көннәрендә –13 градуска кадәр суыта.

Гидрометеоүзәк хәбәр иткәнчә, чәршәмбе – 1 мартта көндез –3...–8, төнлә –6...–11 градус көтелә. Пәнҗешәмбе – 2 мартта тагын да суыграк: көндез –4...–9, төнлә –8...–13. Юлларда бозлавык саклана.

Башлангыч фаразларга караганда, җомга һәм шимбә – 3, 4 март көннәрендә чираттагы циклон йогынтысында болытлы, кар-буранлы һава торышы урнаша. 3 мартта көндез –1...–6, төнлә –7...–12 градус салкын. Шимбә янә җылыта: көндез термометрның терекөмеш баганасы –2...+1, төнлә –3...–8 градус күрсәтәчәк.

Сәламәтлек

Биләүсәдә үк тикшерәсе

Яңа туган сабыйларны хәзер тагын да җентекләп тикшерәчәкләр. Элегрәк сабыйларны биш төрле генетик авыруга тикшерсәләр, хәзер бу сан 36га җиткән.

РКБның генетик консультация мөдире Зөлфия Вафина сүзләренә караганда, әлеге яңалык быел 1 гыйнвардан гамәлгә кергән. Шул вакыт эчендә республикада барлыгы 6,5 мең балага шундый киңәйтелгән тикшерү ясалган.

– Әлеге тикшерү нәтиҗәләре буенча 160 бала хәвеф төркемендә тора. Шуларның 96сының анализ нәтиҗәләре билгеле инде. Аларны кулга алгач, 4 балага тагын да җентекле тикшерү узарга юллама бирдек. Аларда генетик авыру диагнозы раслану ихтималы бик зур, – ди белгеч.

Татарстанда яңа туган балаларга скрининг тикшерүе 1993 елдан бирле ясала. 2006 елга кадәр сабыйларны ике

Илдар Мөхәммәтҗанов

төрле генетик авыруга тикшергән булсалар, аннары аларның санын бишкә җиткергәннәр. Быелдан башлап исә яңа туган сабыйларда киңәйтелгән скрининг ярдәмендә 36 төрле генетик авыруның булу-булмавын тикшерәләр.

– Болар бар да җитди – инвалидлыкка ук китерә торган авырулар. Башлангыч чорда ачыкланса, аларны дәвалау мөмкинлеге арта. Нәселдән килә торган авырулар бик мәкерле. Алар үзләрен тугач ук түгел, вакыт узгач та сиздерергә мөмкин. Шуңа күрә бала туганнан соң ун көн үткәч, сабыйны өстәмә тикшеренү узарга чакырып шалтыраткач, ата-ана еш кына сүзсез кала. «Минем баламның барысы да тәртиптә», – диләр. Форсаттан файдаланып, шуны әйтәсем килә: әгәр баланың сәламәтлеге белгечләрдә шик уятса, өстәмә тикшеренү узу мәҗбүри. Алтынга тиң вакытны юкка сарыф итәргә кирәкми. Соңга калсаң, дәвалау да нәтиҗә бирмәскә мөмкин, – ди Зөлфия Вафина.

Белгечнең бу сүзләрен саннар да раслый. Яңа туган сабыйга ясалган скрининг ярдәмендә ел саен 30–40 балада генетик авыру барлыгы ачыклана. Вакытында ярдәм күрсәткәч, алар тулы канлы тормыш белән яши, ди белгечләр.

Бу скрининг ничек уздырыла соң? Республика клиник хастаханәсенең яңа туган балалар бүлеге мөдире Альбина Идиятуллина сүзләренә караганда, бала туганнан соң, аңа туу турында таныклык бирелә. Шул документ нигезендә аңа скрининг узарга юллама бирәбез. Аңа кадәр табиб-неонатолог ана белән сөйләшә, аңлату эшләре алып бара, аннан язмача ризалык ала. Бары шуннан соң баладан кан анализы алып, скрининг ясала. «Моңа кадәр скрининг бала туганнан соң дүрт көн узгач ясалса, хәзер ул беренче тәүлектә үк башкарыла. Кан алганнан соң, ул медик-генетик консультациягә озатыла», – ди белгеч.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Сүзгә-сүз



Алмаз ГАМИРОВ, Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы терлекчелек тармакларын үстерү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе:

Татар бал кортлары – республиканың байлыгы. Без аларны саклап калырга тиеш. Безгә кадәрге буыннар да еллар буе саклаган. Югалтсак, кичерелмәслек хата булачак.

(«Татар-информ»)

ТАТАРСТАНДА – КАПИТАЛЬ ТӨЗЕКЛӘНДЕРҮ

Быел республикада 7 федераль программа (4 илкүләм проект һәм 3 дәүләт программасы) буенча 178 объектны төзекләндерүгә 5 млрд 50 млн сум акча тотарга җыеналар. 28 республика программасы буенча 1367 объектта 19 млрд 68 млн сумлык эш башкарырга ниятлиләр.

Мәгариф 271 объект **7 млрд 875 млн сум**

Сәламәтлек саклау 147 объект **3 млрд 691 млн сум**

Мәдәният 36 объект **1 млрд сум**нан артык

Яшьләр сәясәте 29 объект **1 млрд 311 млн сум**

Җиде кат тикшерәсе

Мошенниклар Дәүләт хезмәтләре порталы хезмәткәрләре исеменнән шалтырата башлаган. Алар, теге яки бу сәбәп табып, кешеләрнең шәхси кабинетына керергә тырыша.

Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгының матбугат хезмәте хәбәр итүенчә, мондый очраклар Алабуга районында теркәлгән. Кырыгалдарлар, шәхси кабинетка кермәкче булып, смс-хәбәр белән җибәрелгән кодны сорыйлар. Аны кулга төшергән очракта, кешенең шәхси мәгълүматлары белән эш итү мөмкинлеге алалар.

Полиция вәкилләре әйтүенчә, чын хезмәткәрләр беркайчан да смс-хәбәрдәге кодны яки акча күчереп карауны сорамый. Мондый очракта, сөйләшүне өзеп, порталның рәсми номерына шалтыратырга кирәк.



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

КЫТАЙЧА ТЫНЫЧЛЫК УРНАШТЫРУ

Россиялеләр озаклап ял һәм бәйрәм иткән үткән атнада дөньякүләм вакыйгалар динамикасы көчәйде. Вазгыятьнең безнең өчен начар ягы шунда: киеренкелек Россиянең чик сызыклары буйлап үтә һәм Россия – Украина конфликты булудан туктап, Россия – Көнбатыш, Кытай – Көнбатыш бил алышуына әверелеп бара.

Сүз турыдан-туры кораллы бәрелеш турында бармый. Әмма Байденның Польшадагы чыгышы ачык күрсәтә: Россияне стратегик тар-мар итү һәм аның югары җитәкчелеген хөкемгә тарту максаты ачыктан-ачык куелды. Моның өчен көнбатышлылар Россиягә икътисадый басым ясауны көчәйтергә җыена. Авырлык белән булса да санкцияләрнең унынчы пакеты кабул ителде. Яңа пакет нигездә элекке санкцияләрнең үтәлешен контрольгә алуны күздә тота. Мәскәү, зур гына югалтулар белән булса да, тыюлар киртәсе аша сикереп чыгуның юлларын таба. АКШ Россия корычына һәм алюминийга 200 процентлы пошлиналар кертте. Шуңа охшаш адымнарны Европа ясаган иде инде. Финанс системасына күпсанлы чикләүләр кертелде. Россиянең FATF – акча юдыруга каршы оешмада әгъза булып торуы туктатылды. Бу Киев таләбе белән эшләнде. Украиннар Мәскәүне кара исемлеккә кертүне үк сораган иде, әмма әлегә «туктатып тору» дигән формула гына кулланылды. Булган кадәресе дә Россиядән күчерелгән теләсә нинди акчаны «террорны финанслау» дип карарга мөмкинлек бирә.

Башында АКШ торган Көнбатыш коалициясе башка дәүләтләрдән Россиягә мөнәсәбәтләрен ачыклауны таләп итә. Моңа җавап итеп Согуд Гарәбстаны Украинага 100 миллион долларлык гуманитар ярдәм һәм 300 миллион долларлык нефть продуктлары бирәчәген игълан итте. Россиягә каршы коалициягә гарәп көнчыгышы кушылса, бездә хәлләр яман булачак.

Вакыйгалар кискен борылырга торган мизгелдә уен кырына Пекин чыкты. Компартия политбюросы әгъзасы, тышкы сәясәтне билгеләүче иң югары чиновник Ван И Европа дәүләтләрендә булганнан соң, Мәскәүгә килде һәм Путин белән очрашты. Россия – Украина конфликты Кытайга бик зур бонуслар да бирде, билгеле, әмма югалтулар да байтак. Чиннар конфликтны тәгәлләүне куәтләүче як буларак уенга кушылырга тели. Си тарафыннан әзерләнгән 12 пунктлык Кытай планы игълан ителде. Бик матур сүзләрдән торган ул план тормышка ашмаячак, билгеле. Хәтта шул план нигезендә ике як килешү имзаласа да, берни дә барып чыкмаячак, чөнки пунктлар шундый итеп язылган: һәр як аларны үзенчә укый ала. Көнбатыш чин планын шунда ук кире какты. Байден аның Путин өчен сөенеч булачагын һәм Кремль лидерын сөендерергә теләмәвен әйтте. Шольц: «Анда Россия гаскәрләрен чыгару турында пункт җитешми», – диде. Евросоюз исеменнән Жозеп Боррель дә планда мөһим моментлар җитешмәвен ассызыклады. Көнбатыш Кытай Россиягә корал белән ярдәм итәргә тели дип шаулый һәм андый ярдәм күрсәтелсә, Пекинга дәһшәтле санкцияләр белән яный. Ул янау тормышка ашырылса, дөньякүләм икътисад мәтәлчеге озак көттермәячәк.

Россиядә

ӘЙЛӘНЕЧТӘН ЮЛ ТУРЫ

Катлаулы һәм шомлы вазгыятьтә Россиянең тышкы сәүдә оештыручы бюрократиясе үзен гадәттән тыш елгыр һәм инициативалы итеп тота. Моны билгеләп үтми калып булмый. Укучылар, бәлки, хәтерли торгандыр: нефть продуктларына эмбарго кертелгәч, Россиядә мазут проблемасы кискен калкып чыгарга мөмкин, дип язган идек.

Мазутны тышкы базарга сата алмауның бездәге нефть эшкәртү заводларының туктавына һәм мотор ягулыгы дефицитына китерүе ихтимал иде. Проблема, чынлап та, бар ул. Рәсми рәвештә нефть эшкәртү 15 процентка кимер дип санала. Сан зур, әмма куркыныч түгел. Бөтенләй нефть эшкәртү туктатыласы иде, ярдәм көтелмәгән җирдән килеп төште. Американың көндәлек газетасы WSJ Төньяк Африка илләренең, комсызланып, Россия нефть продуктларын сатып ала башлаулары турында яза. Мисыр, Марокко, Тунис, Ливия һәм Алжир Европа эмбарго керткән продуктларны үзләрендә туплыйлар икән. Аларга бензин һәм дизель ягулыгы, мазут кирәкми, билгеле. Үзләре – нигездә, нефть сатучы илләр. Белгечләр әйтүенчә, африкалылар, Россиядән алып, Европага озаталар. Арзанга алып, кыйммәткә сатулары аңлашыла инде. Россия өчен финанс югалтулары зур, әмма яңача сәүдә зуррак бәхетсезлектән коткара.

Кытай, Һиндстан, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре дә, мөгаен, шул ук максаттан Росиядән күпләп мазут сатып алалар. Һиндстан гыйнвар аенда ук бер көнгә 114 мең 500 баррель мазут импортлый башлаган. Кытай тәүлеккә мазут импортын 200 мең баррельгә җиткергән. Берләшкән Гарәп Әмирлекләре 203 мең баррель-тәүлек күрсәткеченә ирешкәннәр. Мазут импортында ярышта Төркия дә алда бара. Европалылар каршы түгел моңа. Иң мөһиме: бәя «түшәм»е саклансын. Алар башта ук шундый кагыйдә керттеләр: Россия чималы башка ил танкерына бушатылса һәм бигрәк тә башка ил ягулыгы белән кушылса, ул Россиянеке дип саналмый. Планетада шундый сәер мазут әйләнеше барлыкка килә инде, нишләтәсең. Россия өчен ике уңайсыз ягы бар моның: арзанга сатарга туры килә һәм Көнбатышның чимал кушылдыгы урынына Африканыкына әвереләсең. Бик үк почетлы түгел инде, әмма түзәргә туры килә. Бәя мәсьәләсе дә үзәкне өзә. Ноябрь аенда Россиянең дизель ягулыгы читкә Европадагы ягулык бәясе белән сатылган. Хәзер баррельгә 35 доллар ташлама ясарга туры килә.

Кайвакыт Россия экспортерлары «түшәм»не ватып та чыккалыйлар икән. Bloomberg агентлыгы Греция яр буйларыннан ерак түгел Россия нефть танкерларының миллионлаган баррель нефтьне башка дәүләтләрнең танкерларына бушатуы һәм санкцияләрне әйләнеп узуы турында шаулый. Грек хакимиятләре, эш нейтраль суларда башкарыла, без кысыла алмыйбыз, дип аклана. Бу очракта табышның төп өлеше кем кесәсенә керәдер, безгә мәгълүм түгел. Без белешкән нефть-газ тармагы белгечләре фикеренчә, сәүдә бик зур коррупцион схемалар белән башкарыла.

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

КАЗАННЫҢ КИЛӘЧӘК ЭШЛӘРЕ

Мобилизациягә эләккән казанлыларга ярдәм, демография, халыкның айлык керемнәрен арттыру... Казан шәһәре Думасының хисап сессиясендә күтәрелгән төп мәсьәләләр бу. Утырышта Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та катнашты.

Сессиядә башкаланың узган елны социаль-икътисадый үсешенә нәтиҗә ясалды, быелга яңа максат-бурычлар билгеләнде. Казан мэры Илсур Метшин сүзләренә караганда, узган ел нәтиҗәләре буенча Казанда барлык төп тармаклар – шул ук шәһәр инфраструктурасы, икътисад, демография юнәлешендә үсеш күзәтелә. Башкалада барлыгы 272,3 миллиард сум салым җыеп алынган. Бу узган ел белән чагыштырганда 60 миллиард сумга күбрәк. Шәһәр бюджетына быелтыр 39,8 миллиард сум күләмендә акча кергән.

Рөстәм Миңнеханов белдерүенчә, Казан республика икътисадына зур өлеш кертә. Күпсанлы чикләүләр кертелүгә карамастан, узган ел Татарстанда бер генә программаның да юкка чыкмавын да искәртте ул. Әйтик, узган ел Казандагы социаль һәм юл инфраструктурасы объектларын төзекләндерү, төзү эшенә барлыгы 68 миллиард сумнан артык акча бүлеп бирелгән.

Рөстәм Миңнеханов Казанның кече һәм урта эшмәкәрлек үсеше буенча алдыруын да искәртте. Бүген Казанда 80 меңнән артык кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары эшли. Тулаем территориаль продуктның 42,2 проценты кече эшмәкәрлек тармагына туры килә. Бүген башкаланың кече һәм урта эшмәкәрлек тармагында барлыгы 350 меңнән артык кеше хезмәт куя. Узган ел шәһәр казнасына әлеге тармактан 7,7 миллиард сумлык салым акчасы кергән. Бу, алдагы ел белән чагыштырганда, 13,5 процентка күбрәк. Шул ук вакытта Рөстәм Миңнеханов эшмәкәрләрне җитештерү тармагына җәлеп итәргә кирәклеген дә искәртте. Әлегә андыйлар нибары 8 процентны гына тәшкил итә.

Рөстәм Миңнеханов фикеренчә, сәламәтлек саклау тармагы мәсьәләләре дә игътибардан читтә калмаска тиеш.

– Соңгы елларда республикада, шул исәптән Казанда медицина оешмаларын яңарту юнәлешендә зур эш башкарылды. Шул ук вакытта социологик тикшеренүләр вакытында башкала халкының нибары 56 проценты гына медицина оешмаларында хезмәт күрсәтү дәрәҗәсеннән канәгать калуын белдергән, – диде Татарстан Рәисе.

Узган ел Казанда уртача хезмәт хакы 63 мең сумга җиткән. Рөстәм Миңнеханов фикеренчә, халыкның керемен арттыру, яшәү шартларын, демографияне яхшырту иң төп бурычларның берсе булып тора.

– Россия Президенты үз Юлламасында 2024 елдан минималь хезмәт хакы күләменең 19242 сум тәшкил итәчәген белдерде. Республика белән Казанны алсак, бездә уртача хезмәт хакы җитәрлек күләмдә. Әмма монда шунысын да истән чыгарырга ярамый: бүген Казанда яшәүче 50 меңнән артык кешенең айлык керемнәре яшәү минимумыннан да түбән. Бу мәсьәләгә аерым игътибар бирергә кирәк, – ди Рәис.

Рөстәм Миңнеханов халык санын арттыруның да мөһимлегенә игътибар итте.

– Казан яшәү өчен иң популяр урыннарның берсе санала. Җанисәп нәтиҗәләре шәһәр халкының 1,3 миллионнан артканлыгын күрсәтә. Әмма балалар азрак туган. Дәүләт, республика өчен бик мөһим мәсьәлә бу, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Илсур Метшин сүзләренә караганда, махсус хәрби операция башкала җитәкчелеге каршында да яңа максат-бурычлар куйган.

– «Игелекле Казан» фонды ярдәме белән гуманитар ярдәм җыеп озатылды. Анда башкаладагы оешмалар, эшмәкәрләр, бу эшкә битараф булмаган һәркемнең өлеше керде. Алар көче белән 38 йөк машинасы белән 725 тонна гуманитар ярдәм озатылды. Без һәр хәрбинең гаиләсе белән элемтәгә кереп, аларның нәрсәләргә мохтаҗ булуын ачыкладык, махсус хәрби операциядә катнашучыларның балаларына ярдәм күрсәтү өчен карарлар кабул иттек, – дип сөйләде мэр.

Рөстәм Миңнеханов та бу урында мобилизацияләнгән ир-егетләрнең гаиләләренә ярдәм итүне төп бурычларның берсе дип атады. Билгеле булганча, Федераль Җыенга Юлламасында Россия Президенты Владимир Путин махсус операциядә катнашучыларның һәм вафат булганнарның гаиләләренә ярдәм фонды булдырылачагын әйтте.

– Фонд булдыру безнең өстән җаваплылыкны төшерми. Муниципаль идарә дә, төрле субъект, оешмалар – барысы да бу эштә актив катнашырга тиеш. Без элеккечә үк хәрбиләргә бәйле сорауларга зур игътибар бирергә тиеш, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Мэрия командасы, депутатлар корпусы, бу эшкә битараф булмаган шәһәр халкы махсус хәрби операциядә катнашучыларга, аларның гаиләләренә, илебезнең яңа төбәкләрендә яшәүчеләргә зур ярдәм күрсәтә. Махсус операция башланганнан бирле гуманитар акциядә башкалада яшәүче меңәрләгән кеше һәм 350 оешма катнашты.

Машина гына түгел

Эшләргә теләк бар, тик эш мәйданнары җитми. Чаллы шәһәр советының хисап сессиясендә әнә шул мәсьәлә күтәрелде. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов исә автокаланың сәламәтлек саклау тармагы җитәкчесен тәнкыйтьләде. Чаллы ни хәлдә? Сессия утырышыннан күзәтү әнә шул хакта.

Былтыр Чаллының алгарышлы үсеш территориясендә алты яңа резидент теркәлгән. Алар 280нән артык кешене эшле итәргә тиеш. «Яңа резидентлар сәнәгатькә 825 миллион сум күләмендә инвестиция җәлеп итәчәк», – дип, фаразларын җиткерде Чаллы мэры Наил Мәһдиев. Яңа эш мәйданнарында светодиодлы яктырткычлар, төзелеш материаллары һәм полимер эшләнмәләр җитештерәчәкләр. Гомумән алганда, «Яр Чаллы» алгарышлы үсеш территориясендә бүген 42 резидент эшли. Алар барлык дәрәҗәдәге бюджетларга 15 миллиард сумнан артык салым күчергән. Җиде ел эшләү дәверендә 7 мең 700гә якын кешене эшле иткәннәр әнә.

Наил Мәһдиев бизнес үсешенә аяк чалган кимчелек турында да әйтте.

– Эшкуарлар сәнәгатькә акча җәлеп итәргә әзер, әмма сәнәгать мәйданнары җитми, – диде шәһәр башлыгы. – Гамәлдәге парклар уртача 90 процентка тулган.

Быел автокалада икенче IT парк та сафка басар дип көтелә. Аның төп резиденты электр ярдәмендә йөрүче машиналар җитештерүче «Атом» компаниясе булачак. Татарстан юлларына чыгачак яңа төр машиналар турында тәгаенрәк КАМАЗ генераль директоры Сергей Когогин сөйләде.

– КАМАЗ яңадан җиңел автомобильләр җитештерү эшенә тотынды. Билгеле булганча, без ил башкаласында «Москвич» автомобильләре проекты белән шөгыльләнәбез. Татарстан турында да онытмыйбыз. «Атом» проекты кысасында шәһәр электромобильләре җитештерә башлаячакбыз. Тәүге «тимер ат»лар быелның маенда ук юлларга чыгачак, – диде генераль директор.

Форсаттан файдаланып, Сергей Когогин заводның уңышлары турында да сөйләде. Санкцияләргә дә карамастан, былтыр җитештерү күрсәткечләрен үстергәннәр. Мәсәлән, 367 миллиард сум керем алганнар. Алдагы ел белән чагыштырганда, бу 7 процентка күбрәк. Былтыр 43 меңнән артык йөк машинасы сатканнар.

Автокалада җәмәгать транспортына бәйле кыенлыклар да бар икән. «Автобус һәм трамвай парклары бик нык искерде», – дип зар белдерде мэр. Әлеге «шактый чыгымлы», әмма «бик күп җирле халыкка кагылган» мәсьәләне хөкүмәт ярдәменнән башка хәл итеп булмаячагын да әйтте.

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов шәһәрнең тагын бер авырткан җиренә төртеп күрсәтте. Баксаң, Чаллыда яшәүчеләрнең 62 проценты гына медицина ярдәменнән канәгать икән. Республика күләмендә дә әлеге күрсәткеч 75 процентны тәшкил итә.

Ә гомуми күрсәткечләргә килгәндә, Чаллыга тел-теш тидерерлек түгел. Моны Рәис тә билгеләп үтте. Республика сәнәгать продукциясенең 12 проценты нәкъ менә биредә җитештерелә. Былтыр автокала федераль һәм республика программалары кысасында 11,1 миллиард сум инвестиция алган.

– Сез – халыкны эшмәкәрлеккә җәлеп итү юнәлешендә дә әйдәп баручыларның берсе, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Җан башына туры килгән кече һәм урта эшкуарлык субъектлары буенча – дүртенче, мәшгульләр саны буенча исә бишенче урында торасыз.

Чаллыда тормыш дәрәҗәсен тагын да яхшырту өчен, республика башлыгы ТКХ, хезмәт хаклары, халыкны эш белән тәэмин итү мәсьәләләренә дә игътибарны арттырырга киңәш итте.

Татарстан тәкъдимнәре әзер

Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Россия Закон чыгаручылар советы президиумы утырышында катнашты. Видеоэлемтә режимында узган чарада Дәүләт Думасы һәм Федерация Советының профильле комитетлары җитәкчеләре, башкарма хакимият органнары вәкилләре, белгечләр төбәкләрдә квалификацияле кадрлар әзерләү, хезмәт базарын үстерү мәсьәләләре, шулай ук җәйге ялны оештыру турында сөйләштеләр.

Утырышта Россия Президенты Владимир Путинның Федераль Җыенга Юлламасын гамәлгә ашыру мәсьәләсенә аеруча зур игътибар бирелде. Аерым алганда, икътисадның төрле тармаклары өчен югары квалификацияле кадрлар әзерләү, югары мәктәпне үзгәртеп кору бурычлары билгеләнде. Закон чыгаручылар югары уку йортларына студентларны максатчан юлламалар буенча җыю мәсьәләсенә аерым тукталды. Дәүләт Думасы мәгариф турында федераль законга үзгәрешләр кертү хакында закон проектын кабул иткән. Документ максатчан юлламалар буенча укытуны камилләштерүгә юнәлдерелгән.

Татарстан бу закон проектын төбәкләр арасында беренчеләрдән булып хуплады. «Республика әлеге мәсьәлә буенча шундук үзенең анык фикерен әйтте», – дип белдерде Дәүләт Думасы Рәисе урынбасары Ирина Яровая.

Фәрит Мөхәммәтшин билгеләп үткәнчә, Татарстан квалификацияле кадрлар әзерләү системасын камилләштерү мәсьәләләре буенча үз тәкъдимнәрен тапшырырга әзер.

– Әлеге мәсьәләне федераль дәрәҗәдә төбәкләрнең законнар чыгаручылары катнашында карап тикшерү бик мөһим һәм вакытлы, – дип басым ясап әйтте республика парламенты башлыгы. – Татарстанда, барлык кыенлыкларга карамастан, быел эшсезләр саны нык кимеде. Ул гына да түгел, бездә эшче кулларның, квалификацияле эшчеләрнең җитмәвен күзәтәбез. Татарстан бу мәсьәләне хәл итү белән ныклап шөгыльләнә.

САТУЧЫ ДА ОТА, АЛУЧЫ ДА

Яшәргә өйрәнәбез

Татарстанда 45 меңнән артык сатучы өйдә торып акча эшли. Ничек итепме? Соңгы арада әбие дә, бәбие дә баш-аягы белән чумган маркетплейслар эшчәнлеге нәтиҗәсе бу. Былтыр республика эшмәкәрләре онлайн сәүдә мәйданнары аша 50 миллиард сумлык товар саткан. Әле бу да чик түгел. Интернет кибетләрне алда ни көтә? Бу хакта Татарстан Министрлар Кабинетында узган брифингта сөйләделәр.



Илдар Мөхәммәтҗанов

«Бүген бирегә килгәндә игътибар иттем: юлда ике-өч тапкыр аркасына зур букча тагып сәпидтә йөрүчене үткәреп җибәрдек. Яңа тармак хезмәткәрләренә шул дәрәҗәдә ияләшеп беттек ки, хәзер моны гадәти күренеш кебек кенә кабул итәбез», – дип, чынбарлыкны әйтеп бирде Татарстан Рәисе каршындагы эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил Фәрит Абдулганиев. Соңгы саннарга караганда, республикада интернетта 45 меңнән артык сатучы теркәлгән. Алдагы ел белән чагыштырганда, күрсәткеч 1,8 тапкыр арткан.

Республикада интернет-кибетләргә «йөрергә» яратучыларга да, биредә сәүдә итәргә теләүчеләргә дә тиешле шартларны булдырырга тырышалар. Чагыштыру өчен, 2021 елда Татарстан картасында электрон сәүдәне оештыру, ягъни тиешле инфраструктураны булдыру күрсәткечләре буенча республиканың унбишләп районы «кызыл» булып янса, былтыр андый районнар саны алты-җидегә генә калган. Интернет сәүдә барыннан да бигрәк Казан, Чаллы, Яшел Үзән, Әлмәт, Түбән Кама шәһәрләрендә, Лаеш, Питрәч, Кукмара, Ютазы һәм Биектау районнарында яхшы эшли икән.

Халык күбрәк үз иткән маркетплейслар да билгеле. Беренче урында – «Вайлдберриз». Әлеге сәүдә мәйданчыгында былтыр 2 миллард сумлык товар сатып алганнар. Икенче урында – «Озон». Беренче өчлеккә «Яндекс Маркет» та эләккән. Сүз уңаеннан, гыйнвар азагында гына Яшел Үзәндә «Озон»ның өченче өлешен төзи башладылар. Беренчесенең складларында 9,8 миллион товар саклана. Биредә көненә 350 мең товарны иясенә озата алалар. Җәйгә кадәр икенче өлешен дә ачарга ниятлиләр.

Татарстан икътисад министры Мидхәт Шаһиәхмәтов сүзләренә караганда, республикада интернет-сәүдәне үстерү программасы 2019 елдан бирле гамәлдә. Аның нәтиҗәсе дә күз алдында.

– Былтыр республикада онлайн сәүдә мәйданнарында 50 миллиард сумлык товар сатканнар. Электрон сәүдәне үстерү республика гына түгел, ә ил күләмендә өстенлекле юнәлешләрнең берсе булып тора. Татарстанда онлайн сату-алуны үстерү программасы 2025 елга кадәр озайтылды, – диде министр.

Кайсы тарафка үсәргә икәне дә билгеле. Баксаң, дөнья күләмендә һәр бишенче сатып алу нәкъ менә интернет-кибетләргә туры килә икән. Россиядә исә һәр тугызынчы кәрзинне генә электрон сәүдә мәйданчыкларында тутыралар.

– Казанда яшәүчеләргә диванда кырын яткан килеш кенә онлайн кибеткә барып кайтуның бернинди кыенлыгы юк. Районнар, кечкенә авылларда яшәүчеләргә дә мондый мөмкинлек булырга тиеш, – ди Фәрит Абдулганиев.

Бу юнәлештә эшли башлаганнар инде. Иң беренче эш итеп... шәһәр һәм район башлыкларын җыеп укытканнар. Бу хакта Чаллы мэры Наил Мәһдиев сөйләде.

– Маркетплейсларда кемнәр эшли дип уйлыйсыз? Бу – хөкүмәткә артык сорау бирмичә, төрле пособиеләр алырга чират тормыйча, үз көнен үзе күреп яшәүчеләр. Интернет сәүдәсе – акча эшләү өчен яхшы мөмкинлек. Чаллыда кече һәм урта бизнес тармагында 90 мең кеше эшли. Өч КАМАЗ заводы халкы кадәр бу! Моңа өстәп, шәһәрдә 30 мең үзмәшгуль теркәлгән. 2021 елда электрон сәүдә өлкәсендә Чаллыда яшәүче 2 мең 700 кеше эшләсә, быелның 1 гыйнварына әлеге сан 5 мең 200 кешедән дә артып китте. Икеләтә үсешкә ирештек. Нәрсә хисабына дисезме? Җитәкчеләрне җыеп укытуның файдасы бик зур. Үзебез аңлагач, башкаларга өйрәтү дә күпкә җиңелрәк булды, – ди Чаллы мэры.

– Эшмәкәрләргә федераль сәүдә мәйданнарына чыгу шактый кыен, ул яктан маркетплейслар бик отышлы, – ди Мидхәт Шаһиәхмәтов. – Бүген онлайн кибетләрдә төймәдән алып автомобильләргә кадәр барысы да сатыла. Бары тик курыкмаска гына кирәк. Үз эшен әле яңа башлаган эшкуарларны да, зур оешма-предприятие вәкилләрен дә эшкә өйрәтү зарур.

Интернет-кибетләрдә иң күп сатылган товарларны да атадылар. Баксаң, «дөнья пәрәвезе»ндә барыннан да бигрәк йорт һәм бакча кирәк-яракларына ихтыяҗ зур икән. Икенче урында – сәламәтлек һәм матурлык өчен товарлар. Беренче өчлеккә электр техникасы да эләккән. Балалар товарлары белән сату итүчеләр дә оттырмый. Бәби киемнәре, уенчыклар – дүртенче урында. Сорау зур булган исемлекнең бишенче баскычында – автомобиль кирәк-яраклары. Менә шундый хәлләр!

Эльвира ВӘЛИЕВА

БЕР ГАИЛӘ – МЕҢ ЯЗМЫШ

Татарстан Республикасының Архив эшләре буенча комитеты оештырган «Без тарихта эзлебез» фестивалендә катнашкан Мөхәммәтшиннар башкалабызның Киров районында үз йортларында көн күрә. «Ата-бабаларыбыз кебек табигать кочагында яшисебез килде», – ди хуҗабикә Ләйсән.

Табигать биргән нигъмәт

– Ирем Илдар белән өч кыз үстерәбез. Олысы Айнага – 9, игезәкләребез Динара белән Рианага – 7 яшь. Ирем – эшмәкәр, үзем ТНВда бухгалтер булып эшләгән идем, – дип сөйли ул. – Хәзер исә тормышымны балаларыма тәрбия бирү эшенә багышларга булдым. Төрле дәресләргә, түгәрәкләргә йөртәм. Өчесе дә музыка белән шөгыльләнәләр. Олы кызым флейтада, курайда уйный, кечеләре флейтадан тыш скрипканы да үз итте. Гөлия Нигъмәтҗанова җитәкчелегендәге «Зиләйлүк» вокаль ансамблендә татар җырларын җырлыйлар, биергә өйрәнәләр. Өйдә барлык фәннәрдән диярлек үзем укытам. Элеккеге, Сталин заманындагы дәреслекләрне кулланабыз. Алар беренче карашка катлаулырак кебек тоелса да, балаларга аңлату җиңелрәк.

Бу гаиләнең һәр иртәсе урман кочагында йөгерүдән башлана икән. Кыш көне ишегалдында бергәләп кар көриләр, чаңгы шуалар, яз көне исә бакчада эш башлана: яшелчәләр, җиләк-җимешләр үстерәләр, су коенырга йөриләр, табигать биргән нигъмәт белән тукланырга тырышалар, икмәкне дә үзләре пешерәләр.

Кыскасы, бөтен максатлары – балаларны эш сөючән итеп үстерү һәм төрле һөнәрләргә өйрәтү. Бу эштә алар ялгыз түгел. Ике яктан да әти-әниләре белән киңәш-табыш итеп яшиләр. Шәҗәрә төзисе булгач, күп эшләрен читкә куеп, тарих чоңгылына чумганнар. Кызлар өчен бигрәк тә мөһим булган бу. Әбиләре-бабалары турында күп нәрсәләр белгәннәр. Дәү әниләре Фирдәүсә белән Фәния сөйләгәннәрне язып та алганнар, хәтерләренә дә уелып калган.

Мөхәммәтшиннарның гаилә архивыннан

Бистә бушап калды

Фирдәүсә әбиләренең нәсел җепләре Яшел Үзән районының Күгәй авылына барып тоташа. Аның әтисе Рәхим Гобәйдуллин, ятим калган биш туганын үстерешергә дип, 12 яшеннән эшли башлый. Архангельскида эшләгән җиреннән сугышка китеп бара. Ике тапкыр яралана. Озак кына госпитальдә ятканнан соң, туган җиренә кайтып, авыл советы рәисе булып эшли. 1951 елда хатынын, ике баласын ала да, товар вагонына утырып, Коми республикасына юл ала. Татарстаннан күп кеше китеп бара анда. Сыктывкарда кәгазь-катыргы комбинаты төзелә башлаган чак була бу. Тайга уртасында авыллар калкып чыга. Рәхим бабалары да Заозерье бистәсендә, кыш башланганчы дип, гаиләсе өчен бүрәнәдән тиз-тиз йорт җиткерә. Буш урын да булмый әле. Агачларны үзләре төплиләр. Бабалары тайгада тимер юл төзи. Пенсиягә чыккач, балалар таралышып калмасын дип, Казанга, Татар бистәсенә кайтып төпләнәләр. Барысын да белемле итәләр. Тәрбияче, төзүче, юрист, педагог, энергетик… Нинди генә һөнәр ияләре юк аларның гаиләсендә. Фирдәүсә әбиләре исә гомере буена баш бухгалтер булып эшли. Татар бистәсендәге бәләкәй генә агач өйләрен бик сагынып искә ала.

– Бу йортыбыз җылы бер учак кебек булды. Әтиәнием, шөкер, бакыйлыкка 11 оныгын, 3 оныкчыгын күреп күчте. Кичләрен әтиебез гармун уйный, ә без кушылып җырлый идек. Әнием Фәүзия Кайбыч районындагы Кече Урсак авылыннан, 11 балалы гаиләдән. Якташлар да булгач, уртага салып сөйләшер сүзләре дә күп иде аларның. Сугыш башланганда, әниемә 17 яшь булган. 1941 елда окоп казыган. Аннан хат ташучы булып эшләгән. Бик матур җырлый иде. Алты баласын музыка дөньясында үстерде. Пластинкаларга кадәр яздырып ала иде. Тирә-юньдә үз өйләрендә торучылар бик күп булды. Бик аралашып яшәдек. Ирем Марат белән дә шунда таныштым. Бик татар җанлы гаилә иде алар. Ул туып-үскән йортта бу нәсел 100 елдан артык тормыш иткән. Бабасы Сафа Тукайның туган җире Кушлавыч авылыннан булган. «Спартак» фабрикасында эшләгән. Ул гына да түгел, бабай янына, аяк киеме тектерергә дип, Казанның бик күренекле кешеләре килә торган иде. Бу һөнәрне иремнең әтисе Мансур да дәвам иттерде әле. Бистәдә яшәүче халык күрше-тирәдәге заводларда, фабрикаларда эшләде. Балалар, нигездә, 35 нче татар мәктәбендә укыдылар. Ял көннәрендә бергәләп, 3–4 сәгать чират торып, Тукай урамындагы мунчада юынып кайта идек. Тузган торакны юкка чыгару программасы буенча, халыкны яңа йортларга күчерделәр. Татар бистәсе шулай итеп бушап калды.

Үзләре дә кимен куймыйлар

Әниләре Ләйсән ягыннан дәү әниләре Фәнияне дә сулыш алмый тыңлый кызлар. Ул аларны Татарстанның тагын башка почмаклары – туган авылы Чүпрәле районы Мунчәли авылы һәм кызларның бабалары Юнысның туып-үскән җире – Нурлат районындагы Үрнәк авылы белән таныштыра. Үзе, мәктәпне тәмамлагач, Казан педагогия институтында белем ала да башта укытучы, аннан балалар бакчасы мөдире булып эшли ул. Ире исә төзүче һөнәрен сайлый. Бергәләп ике кыз үстерәләр.

ШӘҖӘРӘ

«Ватаным Татарстан» газетасы һәм Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитетының уртак проекты

– Әтием Ирфан – гаиләдә 11 баланың берсе, сугыш башланганда, аңа 14 яшь була. Аны колхозда бригадир итеп куялар. «Терлекләрне саклап калыйм дип, фермада куна-төнә яттым. Ачлыктан кырылмас өчен халык, кырдан әрем, кычыткан яфраклары җыеп, икмәк пешерә иде. Үсемлек тамырларын казып ашадылар. Яз башында басудан черегән бәрәңге, кишер җыялар иде», – дип сөйли торган иде әтием. Патша армиясендә унтер-офицер чинында хезмәт иткәндә зур бүләкләргә лаек булган, Гражданнар сугышында катнашкан Сафа бабам өч улы белән фронтка китә. Яраланып кайткач, озак та үтми, дөнья куя. Өч улы сугыш кырында ятып кала. Әнием Язилә Балтач районы Чутай авылыннан. Әнисе авыру, абыйсы сукыр була, шуңа да кечкенәдән тормышны үзе тартып бара, 12 яшьтән колхоз эшенә чыга. Карлы-бозлы чакта чана белән район үзәгеннән орлык ташыганын, сукыр абыйсы белән тау башына үрмәли-үрмәли ботак җыеп йөргәннәрен гел сөйли иде. Укуны тәмамлагач, Первоуральск шәһәренә кирпеч заводына барып урнаша. Шунда бригадир булып эшләгән әтием белән кавышалар да инде, соңрак Мунчәлигә кайтып төпләнәләр. Алты бала тәрбияләп үстерәләр. Ул пенсиягә чыккач та, хезмәт итүдән туктамады. Абыстай булып та йөрде.

Ирем Юнысның нәсел-нәсәбен дә ачы язмыш урап узмаган. Бабасы Харис Башкортстанның Янаул районы Акылбай авылында мулла була. 1937 елда аны «халык дошманы» дип төрмәгә утырталар. Әбисен өч бала белән өеннән куып чыгаралар, кунар урын булмагач, мәчет подвалында йоклап йөриләр. Озак та үтми, әбиләре үлеп китә. Балаларны, җәлләп, әле бер, әле икенче туганнары кунарга кертә. Азрак исәйгәч, бер кызлары – каенанам Зәфинә Үзбәкстанга туганнары янына китеп бара. Шунда армиядә хезмәт итүче Вазыйх исемле Үрнәк авылы егете белән таныша. Туган җиргә кайтып, икесе дә мәктәптә эшлиләр. Мин башлангыч сыйныфны бетергәч, Ульяновск өлкәсенә күченеп киттек. Әни, анда махсус хуҗалыкта эшләп, 11 нче бишьеллык ударнигы булды, социалистик ярышларда җиңү яулады. Биш баланың һәрберсе үз һөнәрен тапты. Арада нефтьчеләр, шәфкать туташы, экономист, төзүчеләр дә бар. Әниебез 13 оныгын үстерешергә дә булышты әле, абыстай булып та йөрде.

Әби-бабаларының, туганнарының язмышларын ишетеп, хәзер Гражданнар сугышының да, репрессия елларының да, Бөек Ватан сугышының да, колхоз тормышының да, илдәге төзелешләрнең дә ни икәнен бик яхшы аңлый кызлар. Шулай булмый ни! Барысы да – иң-иң якын кешеләре башыннан үткән хәлләр бит.

Ике яктагы әти-әниләр дә: «Кызыбыз Ләйсән белән улыбыз Илдарның гаиләсе өчен бик шатланып яшибез», – дигән сүзләр әйтәләр. Балаларга төрле яклап белем бирүләре, физик яктан чыныктырулары, татар телен саклауга, үстерүгә зур өлеш кертүләре аларны бигрәк тә сөендерә. Үзләре дә кимен куймыйлар. Әбиләр бәйләргә, тегәргә өйрәтсә, бабайлар физик тәрбия бирү ягын карыйлар. Аннан бергәләп ял итәләр: Юдино бистәсенең Тимерьюлчылар мәдәният йортында тәмләп кенә оныклары чыгыш ясаганны тыңлыйлар.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

СИРАЕВ МАРАТ ӘШРӘП УЛЫ (01.05.1936 – 26.02.2023)

Татарстан Республикасы җәмәгатьчелеге авыр югалтуга дучар булды. РСФСРның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре, элекке ТАССР авыл хуҗалыгы министры (1983–1988 елларда) һәм Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе рәисе (1994–2000 елларда) Сираев Марат Әшрәп улы 26 февраль көнне 87 нче яшендә арабыздан мәңгегә китте.

Марат Сираев 1936 елның 1 маенда ТАССР Әлки районы Урта Әлки авылында дөньяга килгән. 1964 елда – М. Горький исемендәге Казан авыл хуҗалыгы институтын, 1971 елда Югары партия мәктәбен тәмамлаган.

Хезмәт эшчәнлеген 1956 елда Совет Армиясе сафларында хезмәт итеп кайтканнан соң Әлки МТС трактор-кыр бригадасы учетчигы вазыйфасында башлап җибәргән. 1960 елдан «Энергетик» һәм «Разумовский» совхозларында эшләгән, Әлки, Алексеевск, Апас районнарының җирле хакимият органнары һәм партия оешмаларында җаваплы вазыйфаларны биләгән.

1976 елда ТАССР авыл хуҗалыгы министрының беренче урынбасары итеп билгеләнгән, 1979 елда аңа өстәмә рәвештә Татарстанның колхоз-совхозларына агрохимик хезмәт күрсәтү буенча производство берләшмәсе рәисе вазыйфалары йөкләнгән.

Марат Әшрәп улы 1983–1988 елларда ТАССР авыл хуҗалыгы министры вазыйфасында эшләде.

Аның җитәкчелегендә колхоз-совхозларга агрохимик хезмәт күрсәтүнең бердәм системасына нигез салынды, техник яктан тәэмин итүне модернизацияләү эше алып барылды, алдынгы технологияләр кертелде. Нәтиҗәдә үсемлекчелек һәм терлекчелекне, авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүне үстерүгә зур этәргеч ясалды. Ул шулай ук авыл хезмәтчәннәренең торак-көнкүреш шартларын яхшыртуга, ярдәмче хуҗалыкларны, бакчачылык ширкәтләрен үстерү чараларына зур игътибар бирде.

Марат Сираев – «Прошлое с нами» китабы авторы (2009 елда дөнья күрде). Аның хезмәтендә Татарстанның авыл хуҗалыгын торгызу тарихи яктан җентекле тасвирланган, авыл хуҗалыгы производствосы белән идарә итү мәсьәләләренә зур урын бирелгән.

Марат Әшрәп улы 1988–1991 елларда Татарстан Статистика идарәсе җитәкчесе вазыйфасын биләде, 1991 елда Татарстан Республикасы Дәүләт (парламент) контроле комитеты рәисе итеп сайланды.

Марат Сираев – Татарстан Республикасы сайлау системасын булдыручыларның берсе. Ул 1994–2000 елларда Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Рәисе вазыйфасында хезмәт куйды. Марат Әшрәп улы җитәкчелек иткәндә, әлеге дәүләт органы даими нигездә эшли торган органга әйләнде.

2000–2009 елларда «Казан Кремле» Дәүләт тарихи-архитектура һәм сәнгать-музей тыюлыгында, «Кол Шәриф» мәчете фондында җитәкче вазыйфаларын биләде.

Марат Сираев XI чакырылыш ТАССР Югары Советы депутаты итеп сайланды.

Ул кайда гына эшләмәсен, үз эшенә тугрылыгы, профессионализмы, бетмәс-төкәнмәс көч-энергиясе һәм максатка ирешүдәге ныклыгы белән аерылып торды. Эшлекле сыйфатлары һәм кешелеклелеге, ватанпәрвәрлеге, бик зур җаваплылык хисенә ия булуы, кешеләргә карата игътибарлы мөгамәләсе аңа зур абруй-хөрмәт китерде.

Марат Сираевның күп еллар буе нәтиҗәле хезмәте һәм казанышлары югары дәрәҗәдәге бүләкләр белән билгеләнде. Алар арасында – Хезмәт Кызыл Байрагы, Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен орденнары, «Аерым хезмәтләр өчен», «Фидакарь хезмәт өчен», «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» медальләре, Татарстан Республикасы Мактау грамоталары.

Сираев Марат Әшрәп улының якты истәлеге күңелләребездә мәңгегә сакланыр.

Р.Н. МИҢНЕХАНОВ, М.Ш. ШӘЙМИЕВ, Ф.Х. МӨХӘММӘТШИН, А.В. ПЕСОШИН, Ә.Ә. СӘФӘРОВ, М.Р. ШАҺИӘХМӘТОВ, М.А. ҖӘББАРОВ, М.Г. ӘХМӘТОВ, А.С. КОНДРАТЬЕВ, Ә.С. ГОБӘЙДУЛЛИН, И.Р. МЕТШИН, С.А. ДЕМИДОВ, А.Ф. НИКОШИН, А.Г. ҖИҺАНШИН

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, элекке ТАССР авыл хуҗалыгы министры – Казан шәһәре республика агросәнәгать берләшмәсе советы рәисенең беренче урынбасары, элекке Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе рәисе

СИРАЕВ Марат Әшрәп улы

вафат булу сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе,

СИРАЕВ Марат Әшрәп улы

кинәт вафат булу сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

«Татагрохим» ачык акционерлык җәмгыяте коллективы, Татарстанның «Татсельхозхимия» производство берләшмәсенә нигез салучы, аның беренче җитәкчесе

СИРАЕВ Марат Әшрәп улы

вафат булу сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыруга лаеклы өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Келәнче авыл җирлеге Советы депутаты **Габидуллин** Газинур Әүхәт улы, күпьеллык намуслы хезмәте, һөнәри эшчәнлектә югары күрсәткечләргә ирешүе өчен «Наратлык» шифаханәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директорының хуҗалык мәсьәләләре буенча урынбасары **Гыйбатдинов** Айдар Расык улы, республиканың энергетика тармагын үстерүгә зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Комплекслы Энерго-Үсеш – Инжиниринг» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең «КамЭнергоРемонт-Наладка» филиалы директоры **Кузин** Андрей Анатольевич, республиканың төзелеш тармагын үстерүгә зур өлеш кертүе, күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Евростройхолдинг+» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директорының төзелеш буенча урынбасары **Лебедков** Денис Евгеньевич, граждан оборонасы буенча чараларны гамәлгә ашыруга, гадәттән тыш хәлләрне кисәтүгә һәм аларның нәтиҗәләрен бетерүгә, Татарстан Республикасында халыкны, территорияләрне һәм объектларны янгыннан саклауны тәэмин итүгә зур өлеш кертүе өчен Россия Федерациясе Граждан оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казаларының нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе Кече суднолар буенча дәүләт инспекциясе үзәге башлыгы **Сабиров** Илшат Нуретдин улы, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, театр сәнгатен үстерүгә зур өлеш кертүе өчен «В.И. Качалов исемендәге Казан академия рус зур драма театры» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе башкарма директоры – сәнгать җитәкчесенең әдәби бүлек буенча ярдәмчесе **Хөсәенова** Диләрә Мәсгут кызы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен хезмәт ветераны **Корбанова** Фирдәүс Максут кызы, Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты рәисе урынбасары **Прохорова** Наталья Викторовна **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасары **Кондратова** Наталья Владимировнага, Суд департаментының Татарстан Республикасындагы идарәсе башлыгы урынбасары – баш бухгалтеры **Кукушкин** Алексей Владимировичка, «Челтәр компаниясе» акционер җәмгыятенең тарифлар сәясәте бүлеге башлыгы **Ногманова** Светлана Николаевнага, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының финансларны планлаштыру, исәп һәм хисап бүлеге башлыгы – баш бухгалтеры **Сабырова** Рима Дамир кызына, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының икътисад һәм социаль өлкә тармакларын үстерү бүлеге башлыгы **Мөхәммәдьярова** Зөлфия Ильяс кызына **«Татарстан Республикасының атказанган икътисадчысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЛАРЫ

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык беренче утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ:**

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы кырык беренче утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкару турында.
2. 2022 елда полиция эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министры хисабы.
3. 2022 елда Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең эшчәнлеге турында доклад.
4. «Өстенлек-2030» стратегик академик лидерлык программасы кысаларында 2021 – 2030 елларга «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесен үстерү программасын гамәлгә ашыру турында һәм 2022 елда Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә керткән өлеш хакында хисап.
5. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфалар йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 396-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
6. «Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредитлары бирү турындагы килешүләргә өстәмә килешүләрне раслау хакында» 382-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
7. «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы бюджет законнары актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 393-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
8. «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 11 статьяларына һәм «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 385-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
9. «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 388-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
10. «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында булган мәҗбүри таләпләрне билгеләү һәм аларны куллануны бәяләү һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 391-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
11. «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 389-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
12. «Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 392-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
13. «Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 19 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 386-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
14. «Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының 6 һәм 12 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 394-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
15. «Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 42 һәм 43 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 387-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
16. «Вөҗдан ирекe турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 384-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
17. Татарстан Республикасы Хисап палатасына йөкләмә турында.
18. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Социаль сәясәт комитетының 2019 елның сентябреннән 2023 елның февраленә кадәрге эш чоры өчен хисабы.
19. Балалар учреждениеләрендә педагогик эшчәнлек алып бару чоры балалар учреждениеләрендә педагогик эшчәнлек алып баручы затларга картлык буенча хезмәт пенсиясен вакытыннан алда билгеләү хокукы бирүче эш стажына кертелә торган вазыйфалар һәм учреждениеләр исемлегенә үзгәрешләр кертү турында Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе М.В. Мишустинга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында.
20. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 289051-8 номерлы федераль закон проекты хакында (керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне тикшерүне уздыру тәртибен камилләштерү һәм белешмәләрнең тулылыгы өлешендә).
21. «Дарулар әйләнеше турында» Федераль законның 53 һәм 67 статьяларына һәм «Эшчәнлекнең аерым төрләренә лицензия бирү турында» Федераль законның 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 284099-8 номерлы федераль закон проекты турында (халыкара патентлаштырылмаган «Этанол» исемле дару препаратларын җитештерү күләмен һәм аларның әйләнешен исәпкә алуны камилләштерү өлешендә).
22. «Россия Федерациясе Торак кодексының 161^1 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 272604-8 номерлы федераль закон проекты хакында (күпфатирлы йорт советы рәисенең күпфатирлы йорттагы милекчеләр мәнфәгатьләрен тәкъдим итү процедурасын гадиләштерү өлешендә).
23. «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» Федераль законның 3 статьясына һәм «Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү турында» Федераль законның 11 һәм 16.5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 263340-8 номерлы федераль закон проекты турында (торак-төзелеш кооперативына әгъза итеп алынырга мөмкин булган гражданнар категориясе исемлеген киңәйтү өлешендә).
24. «Россия Федерациясе Җир кодексының 39^{11} статьясына үзгәреш кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Чиләбе өлкәсе Закон чыгару Собраниесе закон чыгару инициативасы хакында.
25. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 3.5 һәм 20.30 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 279585-8 номерлы федераль закон проекты турында (ягулык-энергетика комплексы объектларының куркынычсызлыгын һәм террорчылыктан якланганлыгын тәэмин итү таләпләрен үтәмәгән өчен җаваплылыкны көчәйтү хакында).
26. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 32.4 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 285558-8 номерлы федераль закон проекты турында (конфискацияләнгән җиңел сәнәгать товарларын түләүсез тапшыру мөмкинлеге хакында).
27. Хөкүмәт сәгате: «Татарстан Республикасында Цифрлаштыру елын үткәрү йомгаклары турында».
28. Төрлесеннән.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре, 2023 елның 22 феврале
№ 1834-VI ДС

Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкару турында

«Россия Федерациясендә судьялар статусы турында» Россия Федерациясе Законының 7^1 статьясы һәм «Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ:**

Татарстан Республикасы Чистай суд районы буенча 2 нче суд участогы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкаруны бер елга отставкадагы судья Әхәтов Газинур Зөфәр улына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре, 2023 елның 22 феврале
№ 1835-VI ДС

Истәлеккә – такта

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Кыстыбургерлы татар

Татарстан рестораторлары һәм отельерлары ассоциациясе президенты Зөфәр Гаязовтан, бу хәлне булдырмый калып була идеме, дип сорадык.

– Ничек кенә булмасын, моның бизнес икәнен аңларга кирәк. Әлеге бинаның үзебезнең эшмәкәрләр, аеруча милли ашлар өлкәсендә эшләүчеләр кулына эләкмәве бик кызганыч, әлбәттә. Әгәр яңа хуҗа бинаның традицияләрен сакларга уйласа, без, билгеле, аңа ярдәм итәчәкбез, – дип җавап бирде ул.

Танылган аш-су остасы Резидә Хөсәенова, ничек тә Юныс Әхмәтҗановның мирасын сакларга, аның тәҗрибәсен яшьләргә дә тапшырырга иде, ди.

– Үзебез дә аның китаплары белән үстек. Кызганыч, аның белән шәхсән танышып кала алмадым. Әмма Юныс ага барыбер – минем өчен остаз ул! Хәлемнән килсә, мин аңа һәйкәл куяр идем. Ләкин мөмкинлегемнән чыгып, ел саен аның истәлегенә марафон уздырырга тырышам. Насыйп булса, быел аның исемендәге фестиваль дә үткәрергә иде. Грант язылган, ярдәм булса, бу эшне пешекчеләр, ашчылар әзерләүче уку йортлары белән берлектә башкарасы килә, – дип сөйләде ул безгә. – Татар ашлары йортын булса да саклап кала алмадылар... Юныс ага күпме кунакларны сыйлап сөендергән бина упкынга очты.

Татар халкының моңы, сәнгате, әдәбияты булган кебек, кабатланмас ашау культурасы да булган. Юныс ага – менә шуны яхшы белеп, бүгенгә кадәр җиткергән шәхес. Язучы, эшмәкәр Равилә Шәйдуллина шулай ди.

– Татар ашлары йортының сатылуын белгәннән бирле йөрәгем әрни. Юныс абыйдан соң эшләп китә алмады инде ул. Аның истәлеген һәм, гомумән, татар халык ашларын саклыйсы иде бит. Бу мәсьәләне Хөкүмәт дәрәҗәсендә күтәрергә кирәк. Бу турыда беренче тапкыр гына әйтүем түгел. Юныс абыйның музее булырга тиеш, – диде ул. – Хәзер бит өчпочмакны фарш салып пешерәләр, кыстыбыйга койрык тагып, аннан «кыстыбургер» ясадылар. Болай барсак, койрык белән утырып калабыз бит...

Сүз уңаеннан, Юныс Әхмәтҗановның кызы Фәридә ханым Давидова да әтисе юлыннан киткән – гомерен татлы ризыклар әзерләүгә багышлаган. Танылган аш-су остасының оныгы Искәндәрнең дә туклану өлкәсендә эшмәкәр булуы билгеле. Кызганыч, алар белән элемтәгә чыгып, бу мәсьәләгә карата фикерләрен белә алмадык.

Юныс ӘХМӘТҖАНОВ турында кызыклы фактлар

- Татарстанда «ашханә» сүзенең рәсми рәвештә кулланыла башлавында аның турыдан-туры катнашы бар.
- Данлыклы аш-су остасы Юрий Гагарин, Валентина Терешкова, Юрий Никулин, Александра Пахмутова һ.б. күренекле чордашларын милли ризыклар белән сыйлаган.
- 1964 елда Никита Хрущев ТАССРга сәфәр кыла. Аның белән хушлашу табыны Азнакайдан унике чакрым ераклыктагы Сәпәй урманында әзерләнә. Зур чатырда корылган табын данлыклы Юныс Әхмәтҗанов пешергән затлы татар халык ашлары белән тулган була. Хрущёвка токмач та, өчпочмак та ошый, әмма барыннан да бигрәк тутырган тавык күңеленә хуш килә. Фикрәт Табиев искә төшерүенчә, аны авыз иткәч, Хрущёв: «Бу тавыкларны миңа юлга куегыз», – дип боера.

ЮНЫС ӘХМӘТҖАНОВ РЕЦЕПТЫ БУЕНЧА КОШ ТЕЛЕ

Кирәк булачак:

1 кг он, 10 йомырка, 100 гр сөт, тоз, пешерер өчен 600 гр сары май, камырга салу өчен 30 гр шикәр комы, өстенә сибәр өчен 100 гр шикәр оны, бераз чәй содасы.

Эш тәртибе:

Савытка йомырка сытарга, шикәр комы, сөт яки сөт өсте, кирәгенчә тоз, чәй содасы өстәргә һәм шикәр эреп беткәнче болгатырга. Аннары, он салып, каты итеп камыр басарга. Камырны 1–1,5 мм калынлыкта җәяргә һәм махсус тәгәрмәч белән 3–3,5 см киңлектәге тасмаларга кисәргә. Тасмаларны 4–5 сантиметрлы кыек шакмаклар рәвешендә турап, кайнап торган сары майга салып пешереп алырга. Суытып, шикәр оны сибеп, вазаларга салып, табынга чыгарырга.

РӘХМӘТ ӘЙТЕП КИТТЕ

«АК БАРС» КАПИТАНЫ ДАНИС ЗАРИПОВ КАРЬЕРАСЫН ТӘМАМЛАДЫ

Спорт

Үзе китте, тәҗрибәсе калды. Моңа кадәр «әле уйнап туймадым», «туктарга җыенмыйм» дип кабатларга яраткан, КХЛдагы иң исемлеләрнең берсе саналган хоккейчы профессиональ карьерасын тәмамлавы турында хәбәр итте. Шулай итеп, «Ак барс» 41 яшьлек капитаны, 25 саны астында легендага әйләнгән уенчысы Данис Зарипов белән саубуллашты.

Хоккейчының плей-офф сызыгына якынлашкан мәлдә мондый карар кабул итүе күпләр өчен көтелмәгән булгандыр. Легендар спортчы исә клуб һәм җанатарлар белән вакытын туры китереп саубуллашты: үткән атнада «Ак барс» үз бозында «Металлург» командасын кабул итте. Белгәнегезчә, Данис өчен бу командаларның берсе дә чит түгел. Мәгълүм булганча, Данис Зарипов – «Ак барс» белән Гагарин Кубогын өч, «Металлург» командасы составында ике тапкыр откан шәхес. Әлегә КХЛда аның рекордын кабатлаган спортчы юк.

Тыйнак хушлашу

Билгеле, мондый легендалар белән саубуллашуны купшырак оештырырга да мөмкин иде. Хәтерләсәгез, 2014 елда «Ак барс» өчен шулай ук кадерле булган уенчыларның берсен – Алексей Морозовны Сочида «Беренче канал» кубогына ярышлар вакытында зурлап озатканнар иде. Бер елдан соң уенчы, Казанда хәйрия матчында катнашып, Татарстан җанатарлары белән саубуллашты.

Данис Зарипов та шул юлдан атлыймы? Капитан тыйнак кына саубуллашуны хуплавын әйтте. Әлегә.

– Кире уйларга, саубуллашуны башкачарак оештырырга кирәк дип үгетләүчеләр булды. Әзерләнергә вакытыбыз булмаса да, мин мондый матчны уздырып, карьерамны тәмамлау турында игълан итәргә әзер идем, – диде спортчы соңрак. – Озатуны матур кәгазьгә төреп бирмәдек. Ләкин ул булды. Моның дәлиле – берәүнең дә трибунадан чыгып китмәве. Барысы да яхшы үтте, моннан да яхшырак була алыр иде дип уйламыйм.

«Китәргә вакыт җитте» дигән карарга ничек килүен дә сөйләде Зарипов. Баксаң, командага нәтиҗә китерердәй уенчы булмавын хоккейчы үзе дә таный икән инде. Данис өчен быелгы сезонны уңышлы булды дип әйтеп булмыйдыр да. Спортчы ноябрь аеннан бирле «барслар» белән бозга чыкмаган иде инде. Дөрес, ул спорттан һәм клуб тормышыннан читтә торды дип әйтеп булмый. Җанатарлар белән очрашуларга йөрде, Хоккей академиясенә йөрүче балалар белән күреште, Мәскәүдә кәшәкә сукты, «Алтын алка» матчында балалар белән матч үткәрде.

– Тормышта һәр нәрсәнең үз вакыты була. Мин инде үземнең нәтиҗә китерердәй хәлдә түгеллегемне аңладым. Күпме генә сузсам да, яшь барган саен, сәламәтлек тә үзен сиздерә. «Данис, булды, тукта», – дидем. Соңгы елларда «Кайчанга кадәр уйнаячаксың?» дигән сорауларны еш ишеттем. Һәм мондый сорауларга: «Бозда файдасыз булуымны, командага җиңәргә ярдәм итә алмавымны аңлаганчы», – дип җавап бирә идем. Бүген менә шундый көн инде.

«Егетләр янында булачакмын!»

Бу кичтә көндәшләр өстен чыгып, «Ак барс»ны 6:3 исәбе белән җиңде. Уен беткәч, Данис Зарипов, бозга чыгып, сүз алды. Бозга чыккач, уенчы да хисләрен тыймады. Җанатарлар да. Купшы, алдан хәстәрен күргән озатуларга караганда әнә шундый ихласлары кадерлерәк булуның бер дәлиле инде бу.

– Бүген безнең стадионның шулай тулы булуына мин бик шат. Карьерамның шундый тулы трибуналарда узуы миңа бик ошый. Миңа ышанган барлык җанатарларга рәхмәт әйтәсем килә. Шулай ук боздагы партнерларыма да рәхмәт. «Металлург» һәм «Ак барс» тренерлары штабына рәхмәтлемен. Әлбәттә, үз гаиләмә, «Ак барс» клубы җитәкчелегенә һәм Татарстан Рәисенә ышанычы өчен рәхмәт! – диде Данис Зарипов. – «Ак барс» әле плей-оффта үзен күрсәтәчәк. Мин янәшә булачакмын!

Командадагы егетләр дә бу көнне экс-капитаннарына матур сүзләрне мулдан өләште. Артем Лукоянов дуслык өчен дә, бергә үткәргән сезоннар өчен дә рәхмәтле булуын әйтте. Илья Сафонов легенда белән бер өчлектә уйнавы белән горурлануын белдерде. Дмитрий Кагарлицкий аны кеше буларак та, спортчы буларак та легенда дип атады.

Китсә дә, өметләндереп китте бит әле Данис. Легендар хоккейчы рәсми төстә бозга башка чыкмавын әйтсә дә, команда белән калачак. «Егетләр янында булачакмын. Аларга үз тәҗрибәмне тапшырасым килә. Ул алда торган катлаулы юлны үтәргә булышыр, дип өметләнәм», – диде элеккеге капитан журналистлар белән очрашу вакытында. Без дә өметләнәбез, Данис!

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

tatarstan.ru

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов «Ак барс» клубы җитәкчелеге, тренерлары һәм уенчылары белән очрашты. «Плэй-оффны лаеклы рәвештә башлыйбыз. Җиңү өчен барлык мөмкинлекләрегез дә бар. Күрсәткән уеныгыз өчен рәхмәт. Командабыз белән горурланабыз», – диде Рөстәм Миңнеханов. Очрашуда ул Данис Зариповка дәүләт бүләген тапшырды, аңа «Татарстан Республикасының атказанган физик культура хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде. Көнчыгыш конференциясенең ¼ финалында «Ак барс» «Нефтехимик» белән очрашачак. Беренче ике уен 1 һәм 3 март көннәрендә Казанда узачак. Түбән Камадагы матчлар 5 һәм 7 мартка билгеләнгән.

Зиннәтулла БИЛАЛЕТДИНОВ, «Ак барс» хоккей клубы баш тренеры:

– Данисны җиңү белән куандырасы килгән иде, барып чыкмады. Безнең команда өчен шактый еллар чыгыш ясаган уенчыга рәхмәт әйтәсем килә. Ул – легенда. Татарстан өчен дә, ил өчен дә күп хезмәт куйган кеше. Мин аны 2004 елдан, «Ак барс»ка килгән чорымнан ук хәтерлим. Нинди иде, кем булды! Ул үзен бу дәрәҗәгә күтәрә алды. Мин егетләргә гел әйтәм: хоккей – бер нәрсә, тормыш та бар бит әле. Хоккейдагы бәхетле еллар көннәрдән беркөнне тәмамланырга да мөмкин. Ә тормыш дәвам итә. Тормышта яхшы кеше булырга, балалар үстерергә, үрнәк булырга кирәк. Бу бик мөһим. Даниска да шул теләк. Рәхмәт аңа!

ТӘРӘЗ ТӨБЕМ САЕН ВИТАМИН

Шөгыль

Февраль ахыры булуга карамастан, Чаллыда яшәүче Фәридә Байбикованың биләмәсендә һәрвакыт яз. 20 квадрат метрлы фермасында ул микрояшеллек үстерү белән шөгыльләнә. «Кешеләргә файда, үземә тынычлык китерә». Яраткан шөгыле турында бакчачы әнә шулай ди.

Әлеге эш белән шөгыльләнә башларга кирәклеге турында Фәридәгә сәламәтлеге «хәбәр сала».

– 2020 – пандемия елы иде ул, – дип искә ала Фәридә. – Берничә тапкыр коронавирус белән авырып алгач, яшь булуга карамастан, хәлсезлектән интегә башладым. Сөякләрем сызлый, чәчем коела, тырнакларым да сына иде. Анализлар организмга витаминнар җитмәвен күрсәтте. Күптөрле табибларга мөрәҗәгать итсәм дә, дарулар эчсәм дә, файдасы булмады. Ә остеопатка баргач, ул миңа күп итеп яшел тәмләткеч ашарга кушты. Тик минем очракта укроп һәм петрушка гына ярдәм итми иде. Яшел тәмләткечләрнең һәм микрояшеллекнең файдасы турында күптәннән белә идем, тик аңа кадәр үзем утыртып карау турында башыма да кереп карамады. Әйләнә-тирәдәгеләрнең барысы да вируслар йоктырып авырый башлагач исә, әлеге эшкә тотынырга вакыт җитүен аңладым.

Шулай итеп Фәридә яшел үсемлекләрнең кечкенә үсентеләрен башта тәрәзә төпләрендә үстерә, соңрак ире балконнарын җылыта һәм кирәкле барлык шартларны тудыра. Ә инде 2022 елдан ул ферма арендалап эшли башлаган.

– Барысы да тиз һәм җайлы гына килеп чыкты дип әйтеп булмый. Иң элек тәҗрибәле сити-фермерлардан курслар алдым. Ләкин уңыш хаталар һәм кат-кат эшләп караулар белән генә килде. Эшнең уңышлы баруында сыйфатлы орлыкның роле зур. Акрынлап намуслы эшмәкәрләр белән дә элемтәләр ныгыды. Ирем дә зур ярдәмчем булды. Кәефем төшкән вакытларда ул: «Син бит инде бу эшне башладың, алга таба да шөгыльләнәсең килә. Хаталарыңны тап та алга бар», – дип кабатлап торды, – ди Фәридә Байбикова.

Фәридә Байбикованың шәхси архивыннан

Аның әйтүенчә, микрояшеллек аз калорияле, витаминнарга, антиоксидантларга һәм магний, бакыр, калий, цинк, тимер кебек микроэлементларга бай. Өстәвенә үсемлекләрнең кечкенә үсентеләрен ашау иммунитетка һәм ашкайнату системасына уңай тәэсир итә һәм холестерин дәрәҗәсен дә төшерә. Микрояшеллекне даими рәвештә куллану организмны токсиннардан арындыра һәм күзәнәкләрнең актив яңаруына ярдәм итә.

– Үсемлекләрдә ике яфрак үсү стадиясендә бөтен витаминнар һәм файдалы микроэлементлар туплана. Мәсәлән, 2–3 кашык брокколи үсентесендә бер кәбестә күчәнендәге кадәр витамин бар, – ди ул.

Баштагы вакытларда әлеге файдалы үсентеләрне гаиләсе, туганнары, танышлары өчен генә үстерсә, хәзер аның клиентлары шактый. Күпләрне үзе дә яшеллек үстерергә өйрәткән. Шуңа күрә андыйлар хәзер үз тәрәзә төпләрендә дә файдалы витаминнар үстерә.

– Сатып алучыларымның барысы да – гап-гади кешеләр. Ниндидер зур оешмалар белән эшләмим, чөнки микрояшеллекне озак саклап булмый. Аны, өлгергәч, берничә көн эчендә үк ашап бетерергә кирәк. Ә клиентларга мин аларны үсеп утырган хәлдә китерәм. Шунысы куандыра: хәзер кешеләр сәламәтлегенә игътибар итә, файдалы һәм сыйфатлы ризык ашарга тырыша, – ди Фәридә.

Микрояшеллекне ел дәвамында үстерсә дә, Фәридә барлык эшләрне үзе башкара, ярдәмчеләре юк. Моннан тыш, фермада Витграсс согы ясар өчен бодай үсентеләрен дә үстерә икән. Бодай үсентесе кышын 10–11 көндә өлгерсә, җәен 8–10 көн дә җитә. Шулай итеп, айга ике тапкыр уңыш ала.

– Әлеге сокның файдасын белүчеләр аннан өзелгәннәре юк. Бик файдалы. Аны бер айдан башлап курс белән эчәргә мөмкин. Сокны катырып, суыткычта берничә ай сакларга да мөмкин, – ди ул.

Күренеп һәм сизелеп тора: Фәридә Байбикова эшен бик яратып башкара.

– Мин яшеллекне бик яратып үстерәм, – ди үзе дә. – Ул матур, тәмле һәм файдалы. Эше дә күңелгә ятышлы, тынычландыра. Хезмәтемдә иң нык яратканы – үсемлекләр белән аралашу, фермадагы тынычлык һәм рәхәтлек. Биредә кошлар сайрый, үсемлекләр өчен уңайлы климат булдырылган. Һәм, әлбәттә, кешеләрнең сәламәтлегенә файда китерә алуым белән дә бәхетлемен. Үземнең дә бодай үсентесе согын эчә һәм микрояшеллекне ашый башлагач, өч ай узганнан соң, анализларым яхшырды.

Зөһрә САДЫЙКОВА

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

ТАИФ компанияләре төркеме коллективы, хатыны

САДЫЙКОВА Назирә Шәйхелислам кызы

вафат булу сәбәпле, Татарстан сәламәтлек саклау өлкәсе ветераннары советы рәисе Садыйков Наил Сәлах улының авыр кайгысын уртаклаша.
Назирә Шәйхелислам кызының – изге күңелле, искиткеч мәрхәмәтле кешенең якты истәлеге күңелләребездә мәңгегә сакланыр.

Татарстан Республикасы ветераннары (пенсионерлары) төбәк иҗтимагый оешмасы Советы, тормыш иптәше

САДЫЙКОВА Нәзирә Шәйхелислам кызы

вафат булу сәбәпле, Татарстан Республикасы ветераннары (пенсионерлары) Советы иҗтимагый комиссия рәисе Садыйков Наил Сәлах улының, якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

Татарстан Республикасы мелиораторлары коллективы һәм «Татмелиорация» траст компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте җитәкчелеге, «Татмелиорация» траст компаниясе» ачык акционерлык җәмгыятенең проект-смета идарәсе җитәкчесе урынбасары

ХӘСӘНОВ Раушан Абдулла улы

вафат булу сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

Баш мөхәррирнең беренче урынбасары – ХӨСНУЛЛИН Илнар Хәлил улы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5322 данә
Гомуми тираж – 15277 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 228

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+